| | |
|---|---|
| СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 5 декабре №1

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 118 номерлы карары белән расланган, Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегендә 2022 елның 5 декабрендә 14 сәг. узган гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны Тойгуҗа авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- 320 МТЗ тракторы өчен кар чистарткыч сатып алу;
- янгын гидрантларын сатып алу;
- янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру өчен бетон боҗралар һәм люклар сатып алу;
- боҗралар һәм янгын гидрантлары урнаштыру өчен монтаж эшләре;
- 10 данә урам яктырткычларын сатып алу һәм алмаштыру;
- Узган еллардагы калдыкларны янгын сүндерү гидрантларын урнаштыруга җибәрергә.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 101 граждан кертелде, ә тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 59

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

" Әйе" 58 граждан тавыш бирде;

"ЮК" 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып калды" 1 гражданин тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнары җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре - дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы студентларыннан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертергә сез риза булырсызмы?» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- 320 МТЗ тракторы өчен  кар чистарткыч сатып алу;
- янгын гидрантларын сатып алу;
- янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру өчен бетон боҗралар һәм люклар сатып алу;
- боҗралар һәм янгын гидрантлары урнаштыру өчен монтаж эшләре;
- 10 данә урам яктырткычларын сатып алу һәм алмаштыру;
- Узган еллардагы калдыкларны янгын сүндерү гидрантларын урнаштыруга җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында https//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Тойгуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatar.ru «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин